**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**

Министерство образования и науки Республики Татарстан

Исполнительный комитет муниципального образования "Лениногорский муниципальный район" Республики Татарстан

МБОУ "Гимназия №11 г. Лениногорска"

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 42B2B10034B0C9BC43DD4BF053DD1AA3
Владелец: Шарифуллина Гульнара Тагировна
Действителен с 03.07.2023 до 03.10.2024

РАССМОТРЕНО
Кафедрой татарского языка

___________Касимова Л.А.

Протокол №1

от "28" 08 2023 г.

СОГЛАСОВАНО
Заместителем директора по национальному образования

_________ Самигуллина В.М.

Протокол № 1

от "28" 08.2023 г.

УТВЕРЖДЕНО
Директор МБОУ "Гимназия №11 г.Лениногорска"

__________Шарифуллина Г.Т.

Приказ № 179-ОД

от "29" 08.2023 г.

**Рабочая программа**

учебного курса
«Татарское народное устное творчество (фольклор татарского народа)»
для 6 класса основного общего образования
для образовательных организаций с обучением на родном (татарском) языке
на 2023-2025 учебный год

Составитель: Закирова Залифа Мунависовна

Учитель родного языка и литературы

Лениногорск 2023

## Аңлатма язуы

Хәзерге вакытта Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән татар әдәбиятын укыту программаларында һәм дәреслекләрдә татар халык авыз иҗатын өйрәнүгә бик аз вакыт бирелә. Билгеле, бу әдәбиятка караган дәресләрнең гомуми саны аз булу белән аңлатыла. Урта мәктәптә татар халык авыз иҗаты урта звенода уку елы башында ук өйрәнелә. Һәм татар халык авыз иҗаты байлыгын күз алдына китерү өчен генә дә бу сәгатьләр саны җитәрлек түгел.

Күренекле язучы, әдәбият белгече, М.Горький инде узган гасырның беренче яртысында, ил күләмендә язучылар союзы оешкан чорда ук үзенең бер чыгышында: “Сүз сәнгатенең башы фольклорда” дигән фикерне әйтә. Чыннан да матур әдәбият үзенең эчтәлеге, формасы, жанрлар һәм образлар системасы формалашу ягыннан да фольклорга нигезләнә. Шуңа күрә мәктәп чорыннан ук укучыларны әдәби әсәрне фольклорга нигезләнеп аңларга өйрәтү дә бик мөһим.

Шул ук вакытта халык авыз иҗаты мирасы белән танышу укучы күңелендә туган төбәккә мәхәббәт уяту, патриотизм хисләре тәрбияләү, халкыбызның милли йолаларын, этнографиясен өйрәнү өчен дә мөмкинлек бирә. Халык иҗаты әсәрләре, бала күңелендә кечкенәдән әдәплелек, тәүфикълылык, намуслылык кебек югары әхлак сыйфатлары тәрбияләүдә нигез булып тора.

Балаларга белем һәм тәрбия бирү эшендә фольклор мөмкинлекләреннән файдалану - туган нигезгә, төбәккә, халыкка, аның гореф – гадәтләренә, йолаларына ихтирам тәрбияли. Моңа ирешү юлында дәрестән тыш чаралардан иң уңышлысы – халык иҗатын түгәрәк кысаларында өйрәнү.

**Максат.** Татар халык авыз иҗатын, аның жанрларын, образлар системасын, поэтик үзенчәлекләрен өйрәнү аша укучыларны рухи яктан бай, белемле, иҗади сәләтле, югары мәдәниятле, камил, конкурентлыкка сәләтле, үз иленең патриотлары булган шәхес итеп тәрбияләү.

Бу максатка ирешү өчен түбәндәге **бурычлар** билгеләнде:

- Халык авыз иҗаты үрнәкләре белән танышу, бу өлкәдә эшләүче галимнәр хезмәтен һәм оешмалар эшчәнлеген өйрәнү;

- Халык авыз иҗаты жанрларын, образлар системасын, тематикасын һәм поэтик үзенчәлекләрен өйрәнү аша укучыларны фәнни-тикшеренү эшенә сәләтле һәрьяктан камил шәхес итеп тәрбияләү;
- иҗади омтылыш, халык авыз иҗаты үрнәкләрен, йолаларны өйрәнеп, аларга карата милли горурлык хисләре тәрбияләү.

**Программанын эчтәлеге**

1. **Кереш дәрес. Танышу**. Хезмәт куркынычсызлыгы кагыйдәләрен аңлату.

*Теория.* Ел буена булачак план, эш барышы белән танышу.

2. **Халык авыз иҗатынның башка фәннәр белән бәйләнеше.**

*Теория.* Халык авыз иҗатының төрле фәннәр белән бәйләнеше хакында мәгълүмат бирү. Халык иҗатының тел, әдәбият, тарих, музыка һәм бию сәнгате белән бәйлелеге.

*Практика.* Конкрет мисаллар ярдәмендә сәнгать төрләренең фольклор нигезендә формалашуын аңлату.

3. **Халык иҗатының этнография белән бәйләнеше.**

*Теория*. Халык авыз иҗаты турыдан-туры халыкның тормышы, аның көн-күреше белән бәйле. Милләт яши икән аның теле дә, халык авыз иҗаты да яши дигән сүз. Ә фольклорны саклаучылар, аны үстерүчеләр-кешеләр. Фольклор көнкүрештән башка аерым гына үсә алмый.

*Практика*. Бүгенге көндә дә халык тормышында яши торган йолалар. Укучыларның аларда ни дәрәҗәдә катнашуларын ачыклау.

4. **Йола иҗаты. Йолаларның төркемнәргә бүленеше.**

*Теория*. Йола төшенчәсе турында мәгълүмат. Йолаларның функциональ табигате.

*Практика*. Йолаларның башкарылу урыны, вакыты һәм вазифасына бәйле рәвештә төркемләнүе. Календарь һәм гаилә йолалары.

5. **Календарь йолалар турында төшенчә. Ырымнар.**

*Теория*. Ел дәвамында башкарыла торган игенчелеккә бәйле йолалар, аларның шигъри табигате.

*Практика*. Ырымнар, аларның вазифасы. Авыл хуҗалыгы эшләренә бәйле ырымнар, тормыш-көнкүреш вакыйгалары белән бәйле ырымнар, Табигатьтәге һәм тирә-юньдәге куркыныч затларга юнәлдерелгән ырымнар. Дәвалау ырымнары.

**6. Җир эшкәртү белән бәйле йолалар турында гомуми мәгълүмат.**

*Теория*. Игенчелеккә бәйле йолаларның барлыкка килүе, эволюциясе.

*Практика*. “Бүгенге көндә игенчелеккә бәйле йолалар ни дәрәҗәдә сакланып калган?” Дигән сорауга җавап эзләү.

**7. Иген үстерүгә бәйле фольклор. Нардуган, Нәүрүз, Сөрән, Сабан туе.**

*Теория*. Иген үстерүгә бәйле йолалар, игенне чәчәкәнгә кадәр уздырыла һәм алар булачак уңышны фаразлау, уңышны ниндидер явыз көчләрдән, бәла-казалардан саклау йөзеннән профилактик максатка бәйле булалар.

*Практика*. Нардуган, Нәүрүз- кышкы чорда уздырыла, яңа елны каршылау бәйрәмнәре. Сөрән- кыр эшләренә иң соңгы әзерлекне тикшерү. Сабан туе, иген чәчүне тәмамлау бәйрәме.

**8. Игенне җыюга бәйле йолалар.**

*Теория*. Игенне җыюга бәйле йолаларга игеннәр, яшелчә, җиләк-җимешләр өлгереп, ларның мул булып җитешүенә рәхмәт йөзеннән уздырыла торган йолалар керә.

*Практика*. Төрле өмәләр: урак, печән, сүс, тула каз өмәләре. Сөмбелә бәйрәме- көзге эшләр төгәлләнгәч уздырылган бәйрәм. Фарсыдан кергән. Табигатьнең йокыга талуы белән бәйле бәйрәм.

**9. Гаилә йолалары белән бәйле йолалар турында гомуми мәгълүмат.**

*Теория*. Календарь йолалардан аермалы буларак, гаилә йолалары үз эченә кеше гомеренең иң җитди өч вакыйгасын ала: баланың дөньяга килүен, никах туен һәм үлгән кешене җирләүне.

*Практика*. Әлеге өч вакыйганың бер-берсеннән аерылгысыз рәвештә яшәве.

**10. Бала туу белән бәйле йолалар комплексы.**

*Теория*. Бала тууны көткәндә башкарыла торган йолалар. Аларның туачак баланың сау-сәламәт булуын фаразлауга юнәлдерелүе.

*Практика*. Балага исем кушу. Бала тугач та аны юындырганда, киендергәндә әйтелә торган юаткычлар, бармак уеннары. Күз тию. Ырымнар белән дәвалау. Табигать күренешләренә эндәшү.

**11. Никах туе белән бәйле йолалар комплексы**.

*Теория*. Гаилә коруның бик зур җаваплылык булуы. Шуңа күрә борынгыларның бу мәсьәләгә бик зур әһәмият биреп, гаилә кору алдыннан бик күп компонентлы йолалар уйлап табулары. Аларның бүгенге көндә әһәмияте.

*Практика*. Туй алды, никах туе үзе, туй арты белән бәйле йолалар. Замана туйларында борынгылыкны саклаган йолаларның саклану дәрәҗәсе. Гаилә тәрбиясенең әһәмияте.

**12. Кешене соңгы юлга озату белән бәйле йолалар комплексы.**

*Теория*. Үлгән кешене Ислам дине кануннары буенча соңгы юлга әзерләү.

*Практика*. Үлгән кешене искә алу чаралары. Аның өчесен, җидесен, кырыгын уздыру. Илле беренче көнен билгеләп үтү.

**13. Хәрби хезмәткә озату белән бәйле йолалар.**

*Теория*. Хәрби хезмәткә алыну, аның вакыты, озату белән бәйле ышанулар.

*Практика*. Хезмәткә каралган егеткә кулъяулык чигеп бүләк итү. Икмәк тешләтү. Озату мәҗлесе ясау.

**14. Татар халкының милли киемнәре.**

*Теория*. Милли киемнәр турында мәгълүмат. Хатын-кыз һәм ир-ат киемнәре. Күлмәк, алъяпкыч, камзул, чалбар, җилән, бишмәт, постау, һ.б. Баш киемнәре- түбәтәй, эшләпә, бүрек, калфак, яулык, шәл. Аяк киемнәре- читек, кәвеш, башмак, итек, чабата.

*Практика*. Татар милли киемнәре буенча альбом карау. “Тылсымлы куллар журналы” сәхифәсендә катнашу. Читек, түбәтәй, калфак рәсемнәрен ясау.

**15. Милли бизәнү әйберләре.**

*Теория*. Милли бизәнү әйберләре турында мәгълүмат. Хатын-кыз һәм ир-атларның бизәнү әйберләре. Алка, балдак, беләзек, муенса, чулпы, хәситә, яка чылбыры, каеш, сәгать.

*Практика*. Татар милли бизәнү әйберләре буенча альбом карау. “Тылсымлы куллар журналы” сәхифәсендә катнашу. Чулпы, яка чылбыры рәсемнәре ясау.

**16. Татар халкының милли ашлары.**

*Теория*. Милли ашлар турында мәгълүмат. Салкын, кайнар, еренче һәм икенче ашлар. Камыр ризыклары.

*Практика*. Татар милли ашлары буенча китаплар белән танышу. Чәй эчү.

**17. . Татар халкының йорт-җир, каралты-кура ясау тәртибе.**

*Теория*. Төрле төбәкләрдә яшәгән татарларның йорт салу тәртибе. Хуҗалык итү җайланмларын, абзар-сарайларны ясау тәртибе.

*Практика*. Этнографик чыганаклар белән эшләү. Татар капкасы рәсемен ясау.

**18. Йортларның тышкы һәм эчке бизәлеше.**

*Теория*. Йортларның формасы, күләме. Ак өйләр, кунак өйләре. Йорт һәм өй төшенчәсе. Тәрәзә, ишекләрнең, кәрнизләрнең бизәлеше.

*Практика*. Йортларның эчке бизәлеше. Тәрәзә кашагалары, шамаилләр, сәндерә, сәке һ.б. Йортның эчке күренешенең рәсемен ясау.

**19. Ислам дине йогынтысында формлашкан йолалар.**

*Теория*. Дин белән бергә, дини фольклор формлашу. Шайтан һәм аның золымыннан саклану. Гаилә йолаларында дини катлам.

*Практика*. Дини бәйрәмнәрнең бүгенге көндә уздырылу тәртибе.

**20. Ураза һәм Корбан гаетләре.**

*Теория*. Дини бәйрәмнәр- Ураза һәм Корбан гаетләренең татарлар тормышында урыны.

*Практика*. Корбан чалу. Сәдака бирү, ураза тоту һ.б.

**21. Казан мәчетләренең архитектурасы.**

*Теория*. Казан шәһәрендәге мәчетләр. Аларның тарихлары.

*Практика*. Мәчетләрнең тышкы һәм эчке төзелеше. Мәчеттә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре.

**22. Татар фольклорының башка халыклар фольклоры белән уртаклыклары**

*Теория.* Төрле халыклар фольклорындагы уртаклыкларның формалары.

*Практика.* Фольклордагы уртаклыкларны күзәтү өчен аерым жанрларга мөрәҗәгать.

**23. Кардәш һәм кардәш булмаган халыклар фольклорында йола иҗатындагы уртаклыклар.**

*Теория.* Йола фольклорындагы уртаклыкларның Урта Идел һәм Урал буе халыкларында нигездә бер үк вакытта бәйрәм ителүе, бердәй шартларда, бер географик киңлектә яшәүгә бәйле булуы.

*Практика.* Нәүрүз, Сөрән йолаларындагы уртаклыклар.

24. **Кардәш һәм кардәш булмаган халыклар фольклорының җырларындагы тематика һәм образлар системасындагы уртаклыклар.**

*Теория.* Җыр жанрындагы уртаклыкларның үзенчәлекләрен ачыклау.

*Практика.* Чыганаклар, җыр текстлары белән эшләргә өйрәнү.

**25. Халык иҗатының кеше тормышындагы урыны.**

*Практика.*Халык авыз иҗаты кеше тормышында, аның көнкүрешендә бик әһәмиятле роль уйный. Ул бүген безнең тормышыбызда яши.

26. **Йомгаклау.** Ел дәвамында башкарылган эшкә йомгак ясау.

## Программаның укыту-тематик планы.

| № | Темалар | сәгатьләр | Дата | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес. Нәрсә ул фольклор? | | | |
| 2 | Халык иҗатының башка фәннәр белән бәйләнеше | | | |
| 3 | Халык иҗатының этнография белән бәйләнеше. | | | |
| 4 | Җырлау кагыйдәләре белән танышу. | | | |
| 5 | Татар халык җырлары | | | |
| 6 | «Иске кара урман» | | | |
| 7 | «Гөлҗамал» | | | |
| 8 | «Татарстан кызлары» | | | |
| 9 | Татар халкының йола җырлары. Багу поэзиясе. Бишек җырлары. | | | |
| 10 | Бишек җырларын өйрәнүне дәвам итү. | | | |
| 11 | Балалар фольклорында юаткычлар. | | | |
| 12 | Балалар фольклорында мавыктыргычлар. | | | |
| 13 | Багу поэзиясе. Кабатлау. | | | |
| 14 | Күңел ачу фольклоры. Нәүрүз әйтү. | | | |
| 15 | Күңел ачу фольклоры. Сөрән салулар. | | | |
| 16 | Күңел ачу фольклоры. Эндәшләр. | | | |
| 17 | Күңел ачу фольклоры. Әйтенүләр. | | | |
| 18 | Күңел ачу фольклоры. Үртәвечләр. Такмаклар. | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 19 | Күңел ачу фольклоры. Такмазалар. Тел көрмәкләндергечләр. | | | |
| 20 | Күңел ачу фольклоры. Алдавыч әкиятләр. | | | |
| 21 | Күңел ачу фольклоры. Әкиятләр. | | | |
| 22 | Күңел ачу фольклоры. Мәзәкләр. | | | |
| 23 | Өйрәнгән җырларны, уеннарны кабатлау. Иптәшләре алдында чыгыш ясау. | | | |
| 24 | Уен фольклоры. Уеннар. | | | |
| 25 | Уен фольклоры. Драма уеннары. | | | |
| 26 | Уен фольклоры. Җырлы-биюле уеннар. | | | |
| 27 | Татар халык уен -җыры “Кулъяулыгым” – танышу һәм өйрәнә башлау | | | |
| 28 | Татар халык уен -җыры “Кулъяулыгым” – өйрәнүне дәвам итү. | | | |
| 29 | Татар халык уен - җыры “Челтәр элдем читәнгә!” – танышу һәм өйрәнә башлау | | | |
| 30 | Татар халык уен -җыры “Челтәр элдем читәнгә!” – өйрәнүне дәвам итү. | | | |
| 31 | Уен фольклоры. Алдавычлар. Санамышлар. Шобага әйтешләре. | | | |
| 32 | Имеш төбе җимеш, яки ни өчен ни булган. | | | |
| 33 | Мәкальләр һәм табышмаклар. | | | |
| 34 | Өйрәнгән җырларны, уеннарны кабатлау. | | | |
| 35 | Йомгаклау | | | |

Лист согласования к документу № 59 от 16.04.2024
Инициатор согласования: Шарифуллина Г.Т. Директор
Согласование инициировано: 16.04.2024 10:40

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Шарифуллина Г.Т. | | Подписано 16.04.2024 - 10:41 | - |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН